| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2025 Азево авылы № 2-1

Татарстан Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының 17.05.2022 елның 19-1 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендә кабул ителгән 248-ФЗ номерлы ,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Азево авыл җирлеге Советының 2022 елның 17 маенда кабул ителгән № 19-1 « Азево авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне тормышка ашыру турында»гы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) « төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контрольне үткәргәндә мәҗбүри таләпләр бозылуы ихтималлыгын күрсәтүче индикаторлар исемлеге » кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
« Азево авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Советының 2025елның
1ноябрендә кабул ителгән №2-1
карары белән расланды.

**Төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контрольне үткәргәндә мәҗбүри таләпләрнең бозылу ихтималлыгын күрсәтүче индикаторлар исемлеге.**

1.1. Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән объектның торышында аның таләпләренә туры килмәгән өч яки аннан да күбрәк охшаш очракның 30 календарь көн эчендә ачыклануы турында төзекләндерү өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен һәм закон белән саклана торган кыймммәтләргә зыян китерү (зарар) куркынычын күрсәтә торган, гражданнардан, оешмалардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан килгән, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән алынган һәм (яки) килгән мәгълүматларның дөреслеген бәяләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү нәтиҗәсендә алынган мәгълүматның булуы.

Объектларны һәм төзекләндерү элементларын чистарту буенча эш башкару бурычы йөкләнгән оешмага караган хезмәт күрсәтү территориясендә ике календарь атна эчендә, алдагы охшаш чор белән чагыштырганда, травматологик ярдәмгә мөрәҗәгать итүче гражданнар саны 15% ка һәм аннан да күбрәккә арту.

1.3. Урындагы үзидарә органында вакытлыча корылган коймаларны алу, рөхсәт вакыты чыкканнан соң вакытлы объектларны демонтажлау, рөхсәт вакыты чыкканнан соң агачларны кисү, рөхсәт вакыты чыкканнан соң агачларны һәм куакларны күчерү, рөхсәт вакыты чыкканнан соң капитал төзелеш объектының төзелешен (реконструкциясен) тәмамлау, капитал төзелеш объектының төзелеше (реконструкциясе) туктатылган очракта яки 6 айдан артыкка туктатылган очракта әлеге объектны консервацияләү (саклауга кую) турында мәгълүматларның булмавы.

1.4. Биналарны, корылмаларны һәм башка объектларны төзү (яңарту), үзгәртеп кору турында мәгълүмат булган очракта, аларның фасадларына, шулай ук алар тирәсендәге территорияләргә куела торган таләпләрне (биналарның, корылмаларның фасад паспортлары, төзекләндерү проектлары, төзекләндерү проектлары һ.б.) килештерү турында мәгълүматның җирле үзидарә органында булмавы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru
3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Е.В.Афанасьев